**КАРАР**
**Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**

Карамалы авылы №149 «26 » ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 21.21.2014 №72/3 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (21.09.2016 № 38, 06.09.2017 №63, №101 03.07.2018, 19.03.2019 №128 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү максатларында һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 03.08.2018 ел, №340–ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 03.08.2018 ел, №342-ФЗ федераль законнарны үтәү йөзеннән,

Карамалы авыл җирлеге Советы карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 21.21.2014 №72/3 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә (21.09.2016 № 38, 06.09.2017 №63, №101 03.07.2018, 19.03.2019 №128 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35 статьяда:

- торак-коммуналь комплексының индивидуаль торак төзелеше территориаль Ж1 зонасы өчен күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата максималь дәрәҗәдә чик күләмнәр билгеләү өлешендә-5000 кв. м. шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертергә

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында да веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Р.Ногманов